| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Мөэмин-Каратай авыл җирлеге
Мөэмин-Каратай авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ**

2021 елның 20 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Мөэмин-Каратай авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Мөэмин-Каратай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән: 1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мәэмин-Каратай авылы Механизаторлар урам һәм Нагорная урамы буенча юллардагы чокырларны ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы,Механизаторлар ур., 31Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында

«Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Совет рәисе Ә.А.Ханнанова